ISSN 0868-4545



Салауат күпере



9 Май – Бөек Җиңү көне!



Бөек Җиңүнең 59нчы язы котлы булсын!

Бу хат ерактан Оренбург өлкәсеннән килде. Аны Әсәкәй районы Карамал авылында яшәүче Лилия Шәрифуллина язып җибәргән. Хатны ни өчен журналыбызның нәкъ менә май ае санына бирергә булдык соң? Бу айда Лилиягә 11 яшь тула. Дустыбызны ихлас котлыйбыз! Ләкин хикмәт анда түгел. Хатны укыйк әле, хатны...

Авылым уртасында, мәктәп бакчасында бер һәйкәл бар. Якташыбыз, Советлар Союзы Герое Ягъфәр Әхмәтшинга куелган ул. Ягъфәр абый сугышта катнашкан. Бик кыю, батыр булган. Минем бабамнарның әтиләре дә (мин аларны дәү бабай дип йөртәм) катнашкан сугышта.

Әбием үзенең әтисе турында сөйләде миңа. Аның исеме Зөбәер. Ул да – сугыш ветераны. Фронтка сугышның беренче көннәрендә үк китә. Брест дигән шәһәр янында сугыша. Курск янында бабам авыр яралана. Елга якын госпитальдә ята. 1944 елда беренче группа инвалид булып авылга кайта. Инвалид булса да, колхозда эшли. Әбием белән өч кыз үстерәләр.

Зөбәер бабам хәзер безнең арада юк инде. Дәү әбием исән. Аңа – 94 яшь. Дәү бабамны онытмыйбыз. Зиратка барып каберен чистартып торабыз, чәчәкләр утыртабыз.

Рәхмәт инде хөкүмәткә, дәү бабамның каберенә ак мәрмәрдән таш куйдырды. Урының җәннәттә булсын, Дәү бабам!



© "Салават күпере", 2004 ел



Матур хат җибәргән Лилия. Рәхмәт үзенә!

КАДЕРЛЕ ДУСКАЙ! Менә шундый күренешне күз алдына китереп кара әле.

Елгада көмеш су урынына кызыл кан ага. Сугышның ни икәнен шуннан чамала инде.

Гитлерчылар бөтен илебезне канга батырмакчы булдылар. Аны «Дәү бабаңнар» коткарып калды. Әле кайчан гына «бабаңнар» дип яза идек. Ә бүген сүз бабаңның әтисе, икенче буын бабаң, дәү бабаң турында бара. И бу вакыт... Бигрәк тиз уза. Бактың исә, гитлерчыларны тар-мар итүгә – Бөек Җиңүгә киләсе елның маенда 60 ел тула икән бит инде.

Әйдәле, шушы зур бәйрәмне бергәләп каршылыйк әле, дускай. Бабаңнарның орден-медальләрен барла, аларны кайчан, ни өчен бирелгәнен белеш, өлкәннәрнең сугыш белән бәйле истәлекләрен тыңла һәм безгә хат язып җибәр. «Салават күпере» битләрендә «ХӘТЕР САНДЫГЫ» (ә хәтернең ни икәнен син яхшы беләсең булыр, журналыбызның былтыргы октябрь санында аңлаткан идек) ачабыз. Хатларыгызның «иң-иң»нәре ел дәвамында шул «сандык»та урын алып барачак.

Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ

Сибгат ХӘКИМ

Торыгыз, Мусалар...

Кайвакыт күп төрле
Уйлардан йөдисең...
Килә бер җир буйлап
Кычкырып йөрисем:
Басуда – арышлар,
Бакчада әнисләр
Өлгерде, торыгыз,
Торыгыз, Алишлар...
Кайвакыт бүлмәдән
Качасың юри син...
Килә бер җир буйлап
Кычкырып йөрисем:
Дошманнар тынмаслар,
Коялар яңадан
Кургашлар, торыгыз,
Торыгыз, Курмашлар...
Кайвакыт исним дә
Чәчәкле җил исен,
Килә бер җир буйлап
Кычкырып йөрисем:
Чәчәкләр үсәләр,
Көн саен тормышта
Сез кирәк, торыгыз,
Торыгыз, Мусалар...

(1966.)



Муса ҖӘЛИЛ

Бала йокысы

Ак мамык мендәрнең
Эченә күмелеп,
Ул йоклый, төсенә
Сокланып үләрлек!

Күкрәген тутырып
Еш, иркен сулаудан
Ал бархат ирене
Аз гына суланган.

Битләре – пар алма,
Миләүшә – керфеге.
Тир белән чыланган
Ефәк чәч бөртеге.

Өстеннән ул тибеп
Очырган юрганын.
Өч бөртек кашын да
Җыерган булган ул!

Бадианмы, нәркисме –
Хуш исле кочагы!
Куенында, билгеле,
Иң сөйгән курчагы.

«Шылт» иткән тавыш юк,
Бүлмәдә шундый тын.
Кешеләр сөйләшә
Үзара шыпыртын.

Чү, акрын! Идәнгә
Нык басып йөрмәгез!
Йокласын туйганчы,
Уята күрмәгез!

Бүлмәдә өч чебен
Бар иде, аны да
Шәл белән кудылар
Өлкәннәр ягына.

Күрегез, никадәр
Кадерле баланың
Йокысы да назлы
Күңленә ананың.

(1943, 11 декабрь.)



Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ

Абдулла АЛИШ

Ике улым бар

(Алмаз белән Айвазга)

Һәрбер эшне җитез эшли торган
Корыч кебек ике улым бар,
Ике кулым кебек үсеп килгән
Булышчым бар, ике улым бар.

Ике күзем минем үткен күз,
Күрә кайда дошман посканын,
Ике күзем кебек ике улым
Сизгер саклар илнең постларын!

Шуышмасын дошман тирә-якта,
Колакларым яхшы ишетә,
Мин үлсәм дә, ике улым кала,
Алар ишетер икесе ничек тә.

Ике аягым минем чыдам булды
Ерак поход чыккан чакларда.
Аякларым кебек ике улым да
Сынатмаслар әле ятларга!



«Салават күпере» биргән бәхет


Ришат Шакиров

Табигатьтә май. Тиздән җәй. Каникуллар. Юмарт кояш болында чәчәкләрне өлгертер, урманында җиләген кызартыр, су буенда комлыкны кыздырыр. Рәхәтләнеп ял ит. Кемгә ял, кемгә эш. Күптән түгел генә Балтач районы, Яңгул авылыннан хат алдык. Редакциябезнең дусты Ришат Шакиров язып җибәргән аны. Былтыр җәй Ришат Казанга, апаларына кунакка килгән иде. Көн дә редакциябезгә килеп йөрде ул. Эшләгәнгә эш язган, диләр. Авылда тик утырырга өйрәнмәгән малай редакциядә дә үзенә эш тапты. Язучы абыйларына булышты. Без бинабызның беренче катында язып тордык, ә Ришат язганнарыбызны икенче каттагы компьютерга ташып торды. Хәзер Ришатның хатын бергәләп укыйк.

«Исәнмесез, «Салават күпере» журналында эшләүче абыйлар һәм апалар!

Авылда яшәгәч, җәй эштә үтә инде ул. Куяннар алган идем. Алар балалады. Үзләренә үлән җыеп ашатам. Бозауларга да җәй буена печән ташыйм, су эчертәм.

Казаннан кайткач, сезгә булышып йөрүемне авыл малайларына сөйләгән идем – шаккаттылар. Кызыктылар. Мондый бәхет бөтен кешегә дә эләкми бит ул».

Менә бит, Ришатның ярдәменә без генә шатландык дип уйлаган идек. Үзе дә сөенгән икән. Бер-беребезне гел-гел сөендереп яшик, дускай.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ







Бу матур рәсемнәрне Казандагы 10 нчы татар гимназиясе укучылары ясады.



Рәсемнәрне һәм рәссам малайларны, кызларны фотога **Александр** абыегыз **ЭШКИНИН** төшерде.



Алия МУСИНА



Гөлназ МӨХӘММӘТҖАНОВА



Гүзәл ШӘРИФУЛЛИНА



Алинә АХУНОВА




Гөлназ НИГЪМӘТУЛЛИНА





– Селкенмичә ятыгыз, дип,
Безгә кат-кат әйттеләр.
Без ятабыз, ә үзләре
Әллә кая киттеләр!
Мөслим, Метрәй.





– Сеңлем, сине саклыйм әле –
Беркая да җибәрмим:
Әни бераз эшләсен, дип,
Тотып торам менә мин!
Апас, Олы Бакырчы.



– Әйләнәм дә тулганам –
«Сәяхәт» итәм шулай:
Караватымны биш тапкыр
Әйләнеп чыктым бугай!
Арча, Югары Оры.



– Малайларны кызлардан сез
Аермыйсызмы әллә?!
Данис дигән җегет булам –
Танымыйсызмы әллә?!
Әгерҗе, Янаул.



8 Куянша белән Бүретдин чокырдан чыгарга азапланган керпе малае Энәлине күреп алдылар.



9 Куянша Энәлине чокырдан тартып чыгарды.



10 Куянша белән Бүретдин ары юл тоттылар. Бер аланга килеп чыктылар.



11 Алан уртасында кушкаен үсеп утыра иде.



12 Бүретдин кушкаен арасына кысылып калды.



13 Куянша, бәлага тарыган Бүретдинне ташлап, читкәрәк киткәндәй итте.



14 Бәлага тарыган дустын нишләп ташлап китсен инде Куянша – килде ярдәмгә.



15 Бүретдингә бик-бик оят булды.


Марсель ГАЛИЕВ шигырьләре

Көзге каршында



Үзен күргәч тә көзгедә
песи аптырап калды.
Борынга борын тидереп,
иснәшеп тә карады.
Әмма таныш түгел песи
горур иде, шук иде.
Көзгедән килеп чыгарга
исәбе дә юк иде.
Шуннан песи аны эзләп,
көзге артына чыкты,
аннан да таба алмагач,
мыеклы йөзен чытты.
Көзгедәге песине ул
бик ошатты – аңладым.
Песи телен белмәгәч мин:
«Көзгедә дә син үзең бит», –
дип аңлата алмадым.

Мактанчык



Кем иң еракка йөгерә?
Иң биек өй кемнеке?
Кемдә ул иң матур сумка?
– Минем!
– Миндә!
– Минеке!
Әй, мактана бу Айдар,
Айдар түгел, ул – Алдар...

Аптырагач шундый бер сүз
калды аңа тап булып:
«Айдарларның песие дә
кешни икән ат булып».



Судан кайта үскән кыз

Әнисеннән сорады яз:
– Суга барсынмы?
– Барсын.

Чишмәдән сукмак сорады:
– Сулар алсынмы?
– Алсын.

Нәни чиләкләрен асып,
ул кыз киләме?
Килә.

Мөлдерәмә чиләкләрдә
Кояш көләме?
Көлә.

Аның зур үсеп җитәсен
дөнья беләме?
Белә!



Без – дуртәү

Иң алдан гел туп йөгерә,
аның артыннан – Муйнак.
Алардан соң мин йөгерәм,
арттан җил килә уйнап.

Йөгерәбез дүртәүләшеп,
хәйләкәр туп гел алда.
Әни өйгә чакырмаса,
уйга килми туктау да.

Кайткан чакта иң алда – җил,
Муйнак узалмый җилне.
Ә туп миннән күтәрттергән,
ул уйнап арган инде...

Рәссам Алла АЙСИНА




Тылсымлы таягым булса...


Хәтерлисезме, дуслар, без былтыр журналыбызның 6 нчы санында Казанда яшәүче Равил абыегыз Насыйровның тылсымлы таяк ясавы, шул таяк белән дөнья гизүе, гаҗәеп могҗизалар тудыра алуы турында язган идек. Ә сез, тылсымлы таягыгыз булса, нишләр идегез? Нинди уй-теләкләрегезне үтәсен иде ул таяк? Сездән шул хакта язып җибәрүегезне сорадык.

Редакциягә килгән хатларны укыгач, аларны изге ниятле, чиста, саф күңелле, матур хыяллар белән яшәүче балалар язганы мәгълүм булды. Дусларыбыз Җир йөзендә, шул исәптән Чечняда сугышны туктатырга тели. Их, тылсымлы таяк булса... Авыру һәм гарип балаларны аякка бастырыр идегез, авылларны һәм шәһәрләрне гөлбакчага әверелдерер идегез сез. Шулай бит?! Тик менә Казаннан Руслан атлы малайның хаты гына күңелгә шөбһә салды. «Тылсымлы таягым булсамы... Мин үземә биш катлы йорт салдырыр идем. Аны биек койма белән әйләндереп алыр идем. Минем «Мерседес», «Джип», «Вольво» һәм тагын әллә нинди машиналарым булыр иде. Иделдә үземнең яхтамда, гидроциклымда йөрер идем» дип яза ул. Әйе, матур һәм бай яшәргә һәркемнең хакы бар. Шулай да Русланга чик-чаманы белү, үзеңне генә түгел, башкаларны да кайгырту кирәклеген, эшләп тапкан байлыкның гына бәрәкәтле булуын, куаныч китерүен искәртәсебез килә. Бу җәһәттән Мамадыш районы, Шәдче мәктәбенең икенче сыйныф укучысы Эмил Ямалиев хатын укып китү урынлы булыр. «Безнең авыл урамыннан машина үтә алмый. Асфальт җәйдерер идем. Авыл яшьләре өчен клуб салдырыр идем. Барлык кешеләрне дә бай итәр идем».

Ниятең изге, Эмил. Без әзерләгән махсус бүләк Мамадыш районы, Шәдче авылына китә.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Фокусмы? Бурлашумы?

Фәнис белән Әнис бер партада утыралар.

– Кичә телевизордан фокус күрсәттеләр. И кызык нәмәрсә дә инде ул фокус-мокус дигәннәре! Сиңа бер фокус күрсәтимме? – диде Фәнис партадашына.

– Кирәкми. Аны мин үзем дә күрсәтә алам, – диде Әнис.

Фәнис сиздермичә генә күршесенең сумкасыннан карандаш очлагычын алды.

Менә бер мәл Әнис букчасында казына башлады. Очлагыч кирәк иде аңа – шуны эзләде.

Фәнис, көлә-көлә:

– Фокус менә шушы инде ул! – дип дустына очлагычны сузды.

– Кешедән әйберне сорамыйча алу фокус дип аталмый, бурлашу дип атала, – дип үпкәләде Әнис.

– Мин бит сиңа баштук «Фокус күрсәтимме?» дип әйттем. Нишләп бурлашу булсын!


– Синең әйткәнеңне оныткан идем инде мин. Димәк, син бурлаштың.

– Очлагычны шундук кире кайтардым ич! Шулай булгач, мин сиңа фокус күрсәттем дип сана.


Бәхәс дәвам итте. Кем хаклы – җә, син ничек уйлыйсың?



Рәссам табындагы ризыкларны дөрес тезмәгән. Шулай бит?



7 аерманы тап





Бу агачта ничә кош утыра? Санап кара әле.

Башваткычлар

Рәссам Илдар Нәфиев

Кадерле дускай!

Китап тышлыгы төшерелгән рәсемгә игътибар итеп өлгергәнсеңдер инде. Андагы «Ләбиб Лерон. Кояшны кочкан малай» дигән язуларны да җәһәт кенә укыгансыңдыр. Шундук төшенгәнсеңдер дә: әйе, әйе, шагыйрь Ләбиб абыең Леронның «Кояшны кочкан малай» исемле өр-яңа китабының тышлык сурәте бу!

Шагыйрь абыйның шигырьләр, җырлар, әкиятләр, мәзәкиятләр, шигъри әкиятләр һәм әкият-пьесалардан торган ошбу китабын «Мәгариф» нәшрияты әле күптән түгел генә бастырып чыгарды. Китаптагы матур-матур рәсемнәрнең авторы – «Салават күпере»ндәге күпсанлы сурәтләре аша сиңа бик яхшы таныш булган рәссам Алла Айсина.

Китапка кереш сүз-язманы («Салават күпере»нә менгән малай» дип атала ул) Татарстанның халык шагыйре Илдар абый Юзеев язган. Ләбиб абыең Лерон турында мавыктыргыч итеп, әкият рәвешендә язган әлеге язмасын аксакал шагыйребез болай дип тәмамлый:

Озын буйлы, матур уйлы
һәм мыеклы абый ул.
Үзе бик җитди булса да,
Китап сөйгән һәр баланы
Дусты итеп саный ул.



Яңа китап белән дуслашырга ашык, дускай!



Салават күпере

5(170) — 2004

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Александр ЭШКИНИН фотосы һәм Фәрит МУЛЛАХМӘТ рәсеме.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: ck-sxn@newmail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 28.04.2004 ел.
Басарга кул куелды 28.04.2004 ел.
Кәгазь форматы 60x100 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басылды.
Тиражы 12801 данә. Заказ Э-318.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Ләбиб Лерон

Солдат булдым

**Бабаемның фуражкасын
Киямен дә башыма,
«Мин дә солдат булдым», — диеп
Басам көзге каршына.**

**Аннан шык-шык итеп атлап,
Чыгып китәм урамга:
Малайлар белән бергәләп,
Солдат булып уйнарга.**

